ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

# КАРАР

28.11.2017 ел Яр Чаллы № 5306

«Биклән нефть ятмасы төзелеше.
Станция мультифазных насосов» НГДУ «Прикамнефть»
проекты буенча халык тыңлауларын билгеләү хакында

РФ Шәһәр төзелеше кодексының 28, 45 һәм 46 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасының «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставы, «гавами тыңлаулар уздыру тәртибе турында» нигезләмә нигезендә, кешенең яшәү шартларының, җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектларының хокук ияләренең һәм законлы мәнфәгатьләренең уңай шартларын, хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү максатларында кеше хокукларын яклау максатында

**КАРАР БИРӘМ:**

1. «Биклән нефть ятмасы төзелеше.Станция мультифазных насосов» НГДУ «Прикамнефть» проекты буенча халык тыңлауларын билгеләргә.

2. Билгеләргә:

2.1. Халык тыңлауларын үткәрү вакытын - 25.12.2017 15.00 сәг.;

2.2. үткәрү вакыты - әлеге карар басылып чыккан көннән алып халык тыңлаулары нәтиҗәләре турында бәяләмә бастырылган көнгә кадәр кимендә бер һәм өч айдан да артык түгел;

2.3. үткәрү урыны - «Мәдәният йорты» Биклән авылы, Чкалов ур., 26а йорт адресы буенча;

2.4. тикшерелә торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр белдерү, халык тыңлауларында катнашырга заявкалар бирүөчен адрес: Биклән авылы, Чкалов ур., 30а йорты; (эш көннәрендә - 8.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр);

2.5. чыгыш ясау хокукы белән халык тыңлауларында катнашуга заявкалар бирү срогы - 20.11.2017-15.12.2017 ел.

3. Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлегенә әлеге карарны рәсми матбугат басмасында («Якты юл» («Светлый путь») газетасы) бастырып чыгарырга, Тукай муниципаль районының рәсми сайтында tukay.tatar.ru һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгхълүмат порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны төзелеш һәм халык яшәешен тәэмин итү бүлеге башлыгы урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы Р.Т. Гыйзатуллина